ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
28.06.2024

**К А Р А Р**
№ 598

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында административ регламентны раслау хакында» 2022 елның 12 апрелендәге 410 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында административ регламентны раслау хакында» 2022 елның 12 апрелендәге 410 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)» дип аталган 3.6 бүлекне 3.6.3-3.6.5 пунктлар белән тулыландырырга:

«3.6.3. Урынны торак яисә торак булмаган урын сыйфатында файдалануны тәэмин итү өчен аны яңадан урнаштыру, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр таләп ителмәгән очракта, торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаган урынны торак урынга күчерү турында карар кабул итүне раслый торган документ Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора. Бу очракта күрсәтелгән күчерү мондый урынның билгеләнеше турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән соң тәмамланган дип санала.

3.6.4. Урынны торак яисә торак булмаган урын буларак файдалану өчен аны яңадан урнаштыру, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр башкару таләп ителсә, карар кабул итүне раслый торган документ Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 2 өлешенең 5 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру проектын исәпкә алып, тиешле үзгәртеп кору, һәм

(яисә) яңадан планлаштыру үткәрү һәм (яисә) Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 5 өлешендә каралган документта күрсәтелгән мондый эшләр исемлеген исәпкә алып башка эшләрне үткәрү нигезе булып тора.

3.6.5. 3.6.4 пунктта күрсәтелгән яңадан урнаштыру, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр тәмамлангач, мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән яңадан урнаштыру, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр төгәлләнү турында хәбәрнамәне урыннарны күчерүне гамәлгә ашыра торган органга, күчерелә торган бинаның урнашкан урыны буенча турыдан-туры йә күпфункцияле үзәк аша, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә алар тарафыннан төзелгән хезмәттәшлек турында үзара килешү нигезендә җибәрә.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин